

Мордовиядә гаилә һәм балалар турында кайгырту мәсьәләләренә аерым игътибар бирелә. Дәvләт Советынын «Гаилә» юнәлеше буенча комиссияне житәкләvче Мордовия Республикасы Главасы Артём Здунов житәкчелегендә чаралар комплексы гамәлгә ашырыла. Шул исәптән ярышлар да.

Июль башында халыкара Гаилә конен билгеләп vттек. Шушы жылы, матур, тирән мәгънәле, гаиләдә ир белән хатыннын бер-берсенә мәхәббәтен, тугрылыгын, жылы монәсәбәтен, гаилә бәхетен, vзара килешеп, тату яшәвен чагылдырган әлеге кон хөрмәтеннән тагы бер унган гаиләне Рузаевка районы администрациясе Венера белән Наиль Богаповлар гаиләсе «Б - бәхет, М – Мәхәббәт» гаилә флешмобында катнашалар, дигән.
Венера белән Наиль Богаповлар 15 ел бергә. Олы кызлары Айлита Рузаевканын Беренче гимназиясенен 8нче сыйныфында укый, уллары Айдар – бишенче сыйныфта. Тормыш буйлап «Безнен гаилә - безнен байлык!» дигән девиз белән атлыйлар. Богаповлар милли традицияләргә хөрмәт белән карыйлар. Яраткан бәйрәмнәре -Ураза, Корбан, Сабантуй.
- Ел саен республика Сабантуена барырга тырышабыз. 2022 елда зур колач белән уздырылган Аксеново авылындагы Ботенроссия бәйрәме безгә зур тәэсир калдырды. Узган ел без әтинен кече ватанында, Кочкурово районынын Татар Умысы авылы Сабантуенда катнаштык. Бәйрәм коннәрендә без бергәләп зур остәл янына жыелабыз һәм барлык туганнарыбызны: апа-сенелләребезне, абыйларыбызны, бертуганнарыбызны чакырабыз.
Гаиләбезнен яраткан ризыклары: пәрәмәч, чәкчәк, катлама-урама-роза чәчәге. Ә без vз гаиләбез белән кадерле кешеләргә - әби-бабайларыбызга кунакка йорибез. Олкән буынны игътибарсыз калдырмыйбыз, - дип сойләде Венера Фатих кызы гаиләсе һәм гореф-гадәтләре турында.
Унышлар сезгә! Үз йортында бәхетле булган кеше генә бәхетле. Киләчәгегез якты, тыныч, имин, гаиләләрегез бәхетле булсын!

**Наилә НАСЫРОВА**